# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«23» 11 2022 ел Яр Чаллы ш. №3609

Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегендә җирләрне җирле әһәмияттәге рекреацион билгеләнештәге махсус сакланылучы территорияләр җирләренә кертү һәм аларда махсус сакланылучы территорияләр булдыру турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә җирләрне җирле әһәмияттәге рекреацион билгеләнештәге махсус сакланылучы территорияләр җирләренә кертү, алардан файдалану һәм саклау тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2020 елның 21 октябрендәге 2/11 номерлы карары нигезендә Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

## КАРАР БИРӘ:

1. Кадастр номеры 16:39:102902:83, мәйданы 216996 кв. м, адресы (урнашу урыны тасвирламасы): Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Кече Шилнә авыл җирлеге; җирләр категориясе: авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр булган җир кишәрлеген Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегендә гражданнарның ялын, туризмын, физкультура-савыктыру һәм спорт эшчәнлеген оештыру өчен җирле әһәмияттәге махсус саклануччы территорияләр җирләренә кертергә.
2. Махсус саклана торган территория чикләрен кадастр номеры 16:39:102902:83 булган җир кишәрлегенең чикләренә туры килгән чикләрдә расларга.
3. Тукай муниципаль районының Кече Шилнә авыл җирлегендә кушымта нигезендә җирле әһәмияттәге рекреацион билгеләнештәге махсус сакланылучы территория төзергә.
4. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТУКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ * ИНН 1639031830 р 06-38/09

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның ____ . ____ 3609 номерлы карарына кушымта

